**Татарстан Республикасы**
**Кукмара муниципаль районы**
**Янил авыл җирлеге башлыгы**

# КАРАРЫ

**13 ноябрь 2020 ел** **№6**

**«Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Янил авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 27 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Янил авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Янил авылы, Мәктәп урамы, 18 йорты адресы буенча урнашкан Янил авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2020 елның 28 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Янил авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Янил авылы, Мәктәп урамы, 18 йорты адресы буенча урнашкан Янил авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. 2020 елның 29 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Янил авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Янил авылы, Мәктәп урамы, 18 йорты адресы буенча урнашкан Янил авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Янил авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Янил авылында кышын юлларны карап тоту (кардан чистарту, түгү), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;
- Янил авылында энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, төзекләндерү һәм килешү буенча түләү;

- Янил авылына һәм Янил авылы мәдәният йортына видеокамералар алу (сатып алу) һәм урнаштыру, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- Янил авылында Яңа урам, Профтехквартал урамы буйлап җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (ком һәм вак таш сатып алу, ташу, җәю); проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- балалар мәйданчыгы төзү (балалар өчен МАФ (кече архитектура формалары) сатып алу, кайтарту, урнаштыру), проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү;

- чишмәне төзекләндерү (шланглар сатып алу, траншея казу, коймалар ясау, су җыю урынын төзекләндерү, яшелләндерү), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- Янил авылында канауны тирәнәйтү (экскаватор белән эш), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- Ветераннар аллеясы өчен исемле табличка алу (килешү буенча табличка сатып алу)»?

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Янил авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Янил авыл җирлеге башлыгы: И. Х. Корбанов